

Янгын куркынычсызлыгы кагыйдә-ләрен тогәл үтәргә кирәклеген без барыбыз да яхшы анлыйбыз. Ләкин күп очракта нәкъ менә үзебезнен ваемсызлыгыбыз аркасында котелмәгән һәм аянычлы вакыйгаларга килеп тарыйбыз. Искәртәбез: Мордовия Республикасы Урман, аучылык хужалыгы һәм табигатьтән файдалану министрлыгынын 2024 елнын 5 апрелендәге 224 номерлы боерыгы белән 2024 елнын 8 апреленнән Мордовия Республикасы урманнарында 2024 елнын янгын куркынычлы сезоны башлануы турында игълан ителде.
Язнын беренче коннәреннән башлап кар яуганчыга кадәр янгынга каршы чаралар, шулай ук профилактик максаты белән дә үтә. Республикабыз күләмендә профилактик кисәтү чаралары дәвам итә. Шушы коннәрдә беренче тапкыр Рузаевка районындагы ял базасы территориясендә “Янгыннарга - юк!” дигән масштаблы профилактика чарасы узган.

Кунакларны кызыклы тематик мәйданчыклар коткән. Янгыннан коткару техникасы һәм жиһазлары күргәз-мәсендә теләгән һәркем авария-коткару һәм гидравлик кoралларны, альпинистлык жиһазларны, заманча янгын-коткару техникасын күрә, янгын сүндерү машинасы руле артында утыра, янгын сүндерүченен махсус киемнәрен һәм жылылык кайтаручы костюмны киеп карый алган бу чарада. Белгечләр су коену кагыйдәләре турында да сойләгәннәр, коткару чараларын ничек дорес кулланырга икәнен ачык итеп күрсәткәннәр.
Чарада “Россия Красный крест” Гомумроссия иҗтимагый оешмасынын республика бүлеге белгечләре катнашты, алар беренче медицина ярдәме күрсәтү буенча мастер-класслар үткәрделәр.
Янгын күзәтчелеге музее мәйдан-чыгында уникаль экспонатлар тәкъдим ителгән. Мәсәлән, 19 гасыр янгын насосы, ул ат белән йортелгән. Монда шулай ук тарихи документлар, иске фотолар һәм торле янгын сүндерү коралы белән танышырга момкин, ул торле чорларда нинди техника кулланылганы турында бик яхшы күзаллау бирә. Бер мәйданчыкта теләгән һәркем үзләрен киртәләр полосасын үтүдә сынап карады. Шулай ук балалар команда спорт-күнел ачу уены уйныйлар. Якты күргәзмәләрдән, ижади һәм актив локацияләрдән тыш, кунаклар очен ял базасы территориясендә концерт программасы, сувенирлар ярминкәсе һәм кыр кухнясы оештырыла.


Мужество
Честь
Сила
ДИПЛОМ